# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«29» 10 2025 ел Яр Чаллы №3616

2026 елга Тукай муниципаль районында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 15 статьясы 1 өлеше 11 пункты, «Татарстан Республикасында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең 2025 елның 26 сентябрендәге 01/1607 номерлы хаты нигезендә «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга расларга:

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны;

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирү оештыру юлы белән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид булган укучылар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны;

балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен норматив чыгымнарга төзәтү коэффициентын 0,9 күләмендә.

2. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге финанс-бюджет палатасына балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

«Тукай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе
вазифаларын башкаручы Л.Н. Маняпов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2025 елның 29.10. 3616 номерлы карары белән расланган

«Тукай муниципаль районы » муниципаль берәмлегендә балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү прораммасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, бер укучыга бер елга сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгати-эстетик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 9 441 | 17 142 | 20 490 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 9 941 | 17 642 | 20 990 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 9 341 | 17 042 | 20 390 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 9 541 | 17 242 | 20 590 |

**«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирү оештыру юлы белән сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид булган укучылар өчен өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү прорамма-сының юнәлеше | Терри-ториаль урнашу | Норматив чыгымнар, бер укучыга бер елга сумнарда | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | терәк-хәрәкәт аппараты бозылулары, психик үсеше тоткарлануы, аутистик спектры бозылулары һәм үсешендә күп төрле авырлыклар булган бер укучыга | | | ишетү сәләте начар булган бер укучыга: саңгырауларга, начар ишетүчеләргә, соңыннан саңгырауланганнарга | | |
| | | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм аннан соңгы еллары | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм аннан соңгы еллары |
| Сәнгати-эстетик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 19420 | 31968 | 35316 | 13764 | 23619 | 26967 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 19920 | 32468 | 35816 | 14264 | 24119 | 27467 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | авыл җирлеге | 19320 | 31868 | 35216 | 13664 | 23519 | 26867 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 19520 | 32068 | 35416 | 13864 | 23719 | 27067 |